**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 10.02.2021** **№ 160**

**Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2017 елның 14 мартындагы 634 номерлы «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын көтелгән үтәү йомгаклары һәм 2021 елга республиканың финанс, казначылык һәм салым органнарының мәсьәләләре буенча, 2020 елның 18 декабрендәге Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең уртак коллегиясе беркетмә йөкләмәсен үтәүгә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 14 мартындагы 634 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның исемен яңа редакциядә бәян итәргә:

«Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган аерым категория гражданнарына социаль ярдәм буенча өстәмә чаралар бирү турында»;

1.2. Карарның 1 пунктында «түләүләр,» сүзеннән соң «аерым категория гражданнарына,» сүзләрен өстәргә;

1.3. Карарның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Кушымтадагы Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган аерым категория гражданнарга компенсация түләүләре бирү Тәртибен (алга таба - Тәртип) расларга»;

1.4. Карарның 3 пункты башында «Тәкъдим итәргә» сүзен өстәргә;

1.5. Башкарма комитетның 2017 елның 14 мартындагы 634 номерлы карары белән расланган Тәртипнең 2.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Компенсация түләвен алу шарты булып салым органының ведомствоара хезмәттәшлек тәртибендә вәкаләтле орган тарафыннан соратып алына торган мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычы булмау турында

белешмәләре тора,»;

1.6. Тәртипнең 2.4. пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

« - әлеге Тәртиптә билгеләнгән компенсация түләүләрен алу шартларын үтәмәү»;

1.7. Тәртипнең 2.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6. Башкарма комитетның Мәгариф бүлеген компенсацияләр алучы гражданнар турында мәгълүмат җыю буенча вәкаләтле орган итеп билгеләргә».

2. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге начальнигы Н.К. Әхмәтҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин